**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы**

**Бидәңге авыл җирлегенең Татар Бидәңгесе торак пунктында**

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**12 ноябрь 2019 ел** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бидәнге авыл җирлегенең Татар Бидәңгесе торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бидәңге авыл җирлегенең Бидәңге торак пунктында яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бидәңге авыл җирлегенең Татар Бидәнгесе торак пунктында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүне гамәлгә ашырырга.

2. Аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

- Татар Бидәңгесе авылы эчендәге Ленин ур., К.Маркс ур., М.Җәлил ур. юлларны төзекләндерү;

- Татар Бидәңгесе авылы зиратына капка сатып алу һәм урнаштыру;

-Татар Бидәңгесе авылында һәлак булган сугышчыларга куелган обелискны төзекләндерү (койма кую)?».

**Халык җыенында**
**рәислек итүче** **Р.М. Хусаинов**

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Бидәнге авыл җирлеге башлыгы** **Р.М. Хусаинов**